ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы дәүләт тормышындагы һәм җирле әһәмияттәге аеруча мөһим мәсьәләләр буенча халык фикер алышуы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт тормышындагы һәм җирле әһәмияттәге аеруча мөһим мәсьәләләр буенча халык фикер алышуы турында» 2003 елның 6 августындагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә «һәм җирле әһәмияттәге» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 2 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 3 статьяда «һәм җирле әһәмияттәге», «, муниципаль берәмлек уставы, тиешле вәкаләтле җирле үзидарә органнары карарлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 4 статьяның икенче өлешендә «һәм җирле әһәмияттәге» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 5 статьяда «һәм җирле әһәмияттәге», «яисә җирле бюджетлар» сүзләрен төшереп калдырырга;

6) 3 бүлекне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 1 июле
№ 47-ТРЗ